**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6289**
**23.10.2018**

Яр Чаллы шәһәре территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы янаган яки килеп чыккан очракта халыкны вакытлыча урнаштыру пунктлары исемлеген раслау турында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы янау һәм килеп чыгу зонасына эләгүче Яр Чаллы шәһәре халкын вакытлыча күчерү (урнаштыру) буенча чараларны планлаштыру, тәэмин итү һәм үткәрү буенча бурычларны хәл итү, медицина ярдәме күрсәтү, җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм саклау максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы янаган яки килеп чыккан очракта халыкны вакытлыча урнаштыру пунктлары исемлеген кушымтада каралганча расларга.

2. Вакытлыча урнаштыру пунктларын үз вакытында әзерләү һәм оештыруны контрольдә тотуны Яр Чаллы шәһәренең эвакуация комиссиясенә йөкләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 23 октябрендәге
6289 нчы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясендә
табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы янаган яки
килеп чыккан очракта халыкны вакытлыча урнаштыру пунктлары исемлеге

| Т/с | Вакытлыча урнаштыру пунктлары булдырыла торган оешмаларның исеме | Адрес |
|---|---|---|
| 1. | «9 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Александр Грин исемендәге урам, 8/2 йорт |
| 2. | «Предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 44 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Бумажник бульвары, 3 йорт (17а\18) |
| 3. | «22 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Солнечный бульвары, 2 йорт |
| 4. | «41 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Илдар Маннанов исемендәге урам, 11 йорт |
| 5. | «27 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Тынычлык проспекты, 94 йорт |
| 6. | Яр Чаллы шәһәренең «Предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 34 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Ш. Усманов урамы, 110 йорт |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева